**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 17.12.2020** **№ 947**

# Шәхси яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башкага күчерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

Гражданнар һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тормышка ашыруны, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча структур бүлекчәләрнең эшчәнлеген регламентлаштыруны һәм стандартлаштыруны тәэмин итү максатыннан, “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында” 2010 елның 2 нче ноябрендәге 880 номерлы карарына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Административ регламентларны эшләү һәм раслау тәртибен оптимизацияләү белән бәйле рәвештә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турындагы” 2018 елның 13 июнендәге 676 номерлы карары нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Шәхси яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башкага күчерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламентын расларга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталының рәсми сайтында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта
Расланган
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 17 декабрендәге 947 нче номерлы карары белән

**Шәхси яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башкага күчерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең Административ регламенты**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Шәхси яисә муниципаль милектәге җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башкага күчерү турында карар кабул итү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба - Административ регламент) мөрәҗәгать итүчеләр даирәсен, муниципаль хезмәт күрсәтү стандартын, административ процедураларны үтәү составын, эзлеклелеген һәм срокларын, аларны үтәү тәртибенә таләпләрне, шул исәптән административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләрен һәм административ процедураларны күпфункцияле үзәктә башкару үзенчәлекләрен, административ регламентның үтәлешен тикшереп тору формаларын, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның, муниципаль хезмәтне күрсәтүче органның вазыйфаи затының йә муниципаль хезмәт күрсәтү вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүләрне алучылар: муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органга яисә 210-ФЗ номерлы Законның 1 статьясындагы 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән оешмаларга, яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату белән телдән, язма яисә электрон рәвештә мөрәҗәгать иткән физик яисә юридик затлар йә аларның вәкаләтле вәкилләре.

1.3. Муниципаль хезмәт Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) тарафыннан күрсәтелә.

Муниципаль хезмәтне башкаручы - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ (алга таба – Палата яки Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы).

1.3.1.Башкарма комитетның урнашкан урыны: Биектау т/юл.ст.пос., Кооперативная ур, 5 йорт.

Палатаның урнашкан урыны: Биектау авылы, Полковая ур., 9 нчы йорт.

Палатаның эш графигы:

дүшәмбе, сишәмбе – 8.00 дән  17.00 гә кадәр;
пәнҗешәмбе - 8.00 дән  12.00 гә кадәр
чәршәмбе, җомга – кабул итү көннәре түгел;
шимбә, якшәмбе – ял көннәре.
Төшке аш: 12.00 дән 13.00 гә кадәр.

Ял итү һәм туклану өчен тәнәфес вакыты эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре белән билгеләнә.

Белешмә өчен телефон:

Башкарма комитет: 8(84365)2-30-64; Палата:8(84365) 3-28-54.

Керү шәхесне таныклаучы документлар буенча.

1.3.2. “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайты адресы (алга таба – “Интернет” челтәре): (http://vysokaya-gora.tatarstan.ru).

1.3.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында, шулай ук Палатаның эш урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат алынырга мөмкин:

1) Башкарма комитет (Палата) биналарында урнашкан гариза бирүчеләр белән эшләү өчен дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмат стендлары аша.

2) «Интернет» челтәре аша муниципаль районның рәсми сайтында (http://vysokaya-gora.tatar.ru);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында (http://uslugi.tatar.ru/) (алга таба – Региональ портал);

4) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

5) Башкарма комитетта (Палатада):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон буенча;

язма (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон почта аша.

1.3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат Палата белгече тарафыннан муниципаль районның рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Палатаның биналарында урнаштырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә мәгълүмат стендларында һәм муниципаль районның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.5, 2.8, 2.10, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларында) булган муниципаль хезмәт турында белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп), муниципаль районның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны - Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы)

шәһәр яки авыл җирлегендә "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турындагы" 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә төзелгән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматлар (муниципаль хезмәт нәтиҗәсе) документтагы мәгълүмат нигезендә кертелгән мәгълүматларга туры килмәүгә китергән хата (ялгыш язу, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яки шуның ише хата).

Әлеге Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза адигәндә (алга таба - гариза) муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату аңлашыла (2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 2 маддәсенең 2 пунктында). Гариза ирекле формада яки стандарт бланкта тутырыла.

**2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты**

| Муниципаль хезмәт күрсәтү стандартына таләпләр исеме | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү исеме | Шәхси яки муниципаль милектә булган җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) башка категориягә күчерү турында карар кабул итү | РФ ҖК 8ст. 1п. 3,4пп., № 172-ФЗ Федераль законның 2ст. |
| 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарәнең башкарма-боеру органы исеме | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты<br>Биектау муниципаль районының Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы | РФ ҖК 8ст. 1п. 3,4пп., Палата турында Нигезләмә |
| 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләренең тасвирламасы | -мондый җирләрне бер категориядән икенчесенә күчерү турында акт;<br>- җирләрне бер категориядән икенчесенә күчерү турындагы үтенечнамәне яисә җир кишәрлекләрен бер категория җирләр составыннан икенчесенә күчерү турындагы үтенечнамәне караудан баш тарту;<br>- җирләрне яисә җир кишәрлекләрен мондый җирләр составында бер категориядән икенчесенә күчерүдән баш тарту. | № 172-ФЗ Федераль законның 3ст. 4п. |
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнары белән | Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы үтенечнамәне һәм тапшырылган документларны теркәгән көннән алып ике айдан да артмый. Документлар күпфункцияле үзәк аша тапшырылган очракта, срок аларны Башкарма комитетта теркәгән көннән исәпләнә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк. | 172-ФЗ 3 ст. 4 п. 2 пп. |

| | | |
|---|---|---|
| каралган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору вакыты | | |
| 2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен законнар яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле муниципаль хезмәт күрсәтүләр өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен, аларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1) Үтенечнамә (әлеге административ регламентка 1 нче кушымта);<br>2) Гариза бирүченең шәхесен раслый торган документларның күчермәләре (гариза бирүчеләр- физик затлар өчен);<br>3) вәкилнең вәкаләтләрен раслый торган документ (әгәр гариза бирүче исеменнән вәкил эш итсә);<br>4) үтенечнамә белән гариза бирүче вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслый торган документ;<br>5) Җир кишәрлеге хокук иясенең җир кишәрлеген бер категориядәге җирләр составыннан икенчесенә күчерүгә ризалыгы, моңа мондый җир кишәрлегенә сервитут билгеләү турында килешү төзелгән зат хокук иясе булган очрак керми;<br>6) шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан (мөрәҗәгать итүчеләр - шәхси эшмәкәрләр өчен) яисә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (мөрәҗәгать итүчеләр - юридик затлар өчен);<br>7) Выписка из Единого государственного реестра недвижимости на земельный участок, перевод которого из состава земель одной категории в другую предполагается осуществить;<br>8) федераль законнарда аны үткәрү каралган очракта дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе; | № 172-ФЗ Федераль законның 2ст. 4п. |

| | | |
|---|---|---|
| | 1 - 5 пунктчаларында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль тапшырылырга тиеш.<br>Әгәр милек хокукы Бердәм дәүләт күчемсез мөлкәт реестрында теркәлгән булса, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән мөстәкыйль рәвештә тапшырырга хокуклы.<br>Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче башкарма комитетта шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм кушып бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат);<br>почта аша.<br>Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән кул куелган электрон документ рәвешендә, гомуми керүнең мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләре, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм мөрәҗәгать | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында алыналар: | |

| | | |
|---|---|---|
| итүче тәкъдим итәргә хокуклы башка оешмалар карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документларны үз карамагында тоткан дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә башка оешмалар | 1) Бер категориядәге җирләр составыннан икенчесенә күчерү күздә тотыла торган җир кишәрлегенә хокуклар турында күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>2) Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан яисә юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;<br>3) Федераль законнарда каралганча, дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе.<br>Гариза бирүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда аталган документларны таләп итү тыела.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмавы гариза бирүченең хезмәт күрсәтүдән баш тартуына нигез булып тормый. | |
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартыла, әгәр үтенечнамә тексты һәм (яисә) кушып бирелә торган документларны укырга мөмкин булмаса яисә тексты булмаса. | |
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигез каралмаган.<br>Үтенечнамәне караудан баш тарту өчен нигезләр:<br>1) тиешле булмаган зат үтенеч белән мөрәҗәгать итте; 2) үтенечнамәгә җир законнары таләпләренә | №172-ФЗ Федераль законның 2ст. 3п. |

| | | |
|---|---|---|
| | документлар, составы, рәвеше яисә эчтәлеге туры килми торган документлар кушып бирелгән.<br>2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:<br>1) федераль законнар нигезендә мондый җирләр составындагы җирләрне яисә җир кишәрлекләрен бер категориядән икенчесенә күчерүгә чикләү йә мондый күчерүне тыю билгеләнү;<br>2) федераль законнарда үткәрелүе каралган очракта дәүләт экология экспертизасының тискәре бәяләмәсе булу;<br>3) территориаль планлаштыруның расланган документлары һәм территорияне планлаштыру документлары, җир төзелеше документлары белән соратып алына торган җирләрнең яисә җир кишәрлекләренең максатчан билгеләнеше туры килмәве билгеләнү | № 172-ФЗ Федераль законның 4ст. |
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган (бирелә торган) | Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр юк. | |

| | | |
|---|---|---|
| документ (документлар) турында белешмәләр | | |
| 2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәт күрсәтүләр өчен, шул исәптән мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм мондый хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чиратның максималь вакыты | Чират булган очракта муниципаль хезмәт алуга гариза бирү - 15 минуттан да артмый.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда, чиратның максималь көтү срогы 15 минуттан артмаска тиеш | |
| 2.13. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәт һәм хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең соратуын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән вакыттан бер көн эчендә.<br>Электрон формада ял (бәйрәм) көнендә кергән сорату ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратулар тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре куелган һәм һәрбер муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазландырылган биналарда башкарыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| кирәкле документлар исемлеге белән мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедияле мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларга инвалидлар өчен үтемлелекне тәэмин итүгә таләпләр | Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин итеlә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм аларның чикләрендә хәрәкәт итү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркемгә мөмкинлеге һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдаланып, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә) муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең | Муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәркем өчен мөмкин булуы күрсәткечләре булып тора:<br>Палата бинасының җәмәгать транспортының һәркем файдалана алырлык зонасында урнашкан булуы;<br>кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итеlә торган биналар булу;<br>мәгълүмати стендларда, Биектау муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге мәгълүмати ресурсларында, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәтләр алуда тоткарлыкларны узарга ярдәм итү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфаты түбәндәгеләр булмау белән характерлана: | |

| | | |
|---|---|---|
| күпфункцияле үзәгендә, дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәтләрне Федераль законның 15.1 статьясында каралган күпфункцияле үзәкләрдә (комплекслы сорату) берничә дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату юлы белән муниципаль хезмәтне алу мөмкинлеге яки мөмкин түгеллеге | гариза бирүчеләрдән документлар кабул иткәндә һәм биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозу;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата әдәпсез, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында сорату биргәндә һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның да, мөрәҗәгать итүченең дә бер тапкыр үзара хезмәттәшлеге күздә тотыла. Хезмәттәшлек озынлыгы регламент белән билгеләнә.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ) муниципаль хезмәт күрсәткәндә, КФҮ ерак эш урыннарында консультация, документларны кабул итү һәм бирү белән КФҮ белгече шөгыльләнә.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан mfc.tatar.ru сайтында, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) күрсәтүнең бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/), КФҮ дә алынырга мөмкин. | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен (муниципаль | Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә алу тәртибе турында консультацияне Интернет-кабул итү бүлмәсе яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алырга мөмкин. | |

| | | |
|---|---|---|
| хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелсә) һәм электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган. | Муниципаль хезмәт электрон рәвештә күрсәтелгәндә, мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:<br>а) Бердәм порталда яисә Региональ порталда урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;<br>б) региональ порталның «Шәхси кабинет»ын гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны электрон документ рәвешендә бирергә.<br>Региональ порталның «Шәхси кабинет»ын кулланып муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар җибәрелгәндә, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланыла. Мөрәҗәгать итүче гади электрон имзаны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 июнендәге 634 номерлы карары белән каралган очракларда кулланырга хокуклы;<br>в) электрон рәвештә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаларның үтәлеше турында белешмәләр алырга;<br>г) Региональ портал ярдәмендә муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;<br>д) муниципаль хезмәтне электрон документ рәвешендә күрсәтү нәтиҗәсен алырга;<br>е) Бүлекнең, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәткәндә кылган гамәленә | |

| | | |
|---|---|---|
| | (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итүче муниципаль районның рәсми сайты, Региональ портал, федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталын файдаланып шикаять бирү. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре

3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы.

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге административ процедураларны үз эченә ала:

- үтенечнамәне һәм тапшырылган документларны кабул итү һәм теркәү;
- үтенечнамәне һәм тапшырылган документларны карау;
- җирләрне бер категориядән икенчесенә күчерү яисә җир кишәрлекләрен бер категория җирләр составыннан икенчесенә күчерү турында карар кабул итү;
- мөрәҗәгать итүчегә документларны теркәү һәм җибәрү (бирү).

3.1.2. Муниципаль хезмәтне электрон рәвештә күрсәткәндә административ процедураларның (гамәлләрнең) эзлеклелеге:

Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәткәндә административ процедураларның (гамәлләрнең) эзлеклелеге 3 бүлекнең 3.1 бүлекчәсенең 3.1.1 пунктында күрсәтелгән гамәлләрнең эзлеклелегенә туры килә.

3.1.3. Күпфункцияле үзәк тарафыннан башкарыла торган процедуралар (гамәлләр) исемлеге:

- гаризаны һәм тапшырылган документларны кабул итү һәм теркәү;
- муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.2. Үтенечнамәне һәм тапшырылган документларны кабул иткәндә һәм теркәгәндә административ гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы.

Административ процедураны башлау өчен мөрәҗәгать итүченең язма үтенечнамә һәм документлар биреп, башкарма комитетка мөрәҗәгать итүе нигез булып тора.

Документлар кабул итү өчен җаваплы белгеч документларны әлеге административ регламентның 2.7 бүлекчәсендә күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булуга тикшерүне гамәлгә ашыра.

Югарыда күрсәтелгән нигезләр булмаган очракта, документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч билгеләнгән тәртиптә аларны терки һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы белгечкә җибәрә.

Документларны кабул итү һәм теркәү өчен җаваплы белгеч баш тарту өчен нигезләр булганда, мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган документлардагы ачыкланган җитешсезлекләрнең эчтәлеген аңлата, аларны бетерү буенча чаралар күрергә тәкъдим итә һәм документлар пакетын кире кайтара.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе булып кергән үтенечнамәләрне һәм документларны теркәү яисә аларны кабул итүдән баш тарту тора. Гамәлләрне башкару срогы 1 эш көненнән артмаска тиеш.

3.3. Үтенечнамәне караганда административ гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы.

Кергән һәм билгеләнгән тәртиптә теркәлгән үтенечнамәне һәм документларны муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы белгеч карый.

3.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы белгеч үтенечнамәне һәм тапшырылган документларны караганда әлеге Административ регламентның 2.8 бүлекчәсенең 1 пунктындагы 1,2 пунктчаларында. күрсәтелгән үтенечнамәне һәм тапшырылган документларны караудан баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын билгели.

Мондый нигезләр булганда, үтенечнамә һәм тапшырылган документлар кызыксынган затка, үтенечнамә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булган сәбәпләрне күрсәтеп, Бүлеккә кергән көннән алып утыз көн эчендә кире кайтарылырга тиеш.

3.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы белгеч үтенечнамәне һәм тапшырылган документларны караганда әлеге административ регламентның 2.8 бүлекчәсенең 2 пунктындагы 1-3 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең булу-булмавын билгели. Мондый нигезләр булганда җирләрне яисә җир кишәрлекләрен мондый җирләр составында бер категориядән икенчесенә күчерүдән баш тарту турында карар кабул итә, ул мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә).

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе булып, җирләрне яисә җир кишәрлекләрен мондый җирләр составында бер категориядән икенчесенә күчерүдән баш тарту турында яисә үтенечнамәләрне һәм тапшырылган документларны кызыксынган затка кайтару (карау өчен үтенечнамә кабул итүдән баш тарту) турында акт кабул итү тора.

Югарыда күрсәтелгән гамәлләрне башкару срогы үтенечнамә һәм документлар бүлегенә кергән көннән алып ике айдан артмаска тиеш.

3.4. Җирләрне бер категориядән икенчесенә күчерү яисә җир кишәрлекләрен бер категория җирләр составыннан икенчесенә күчерү турында карар кабул иткәндә административ гамәлләрнең эзлеклелеген тасвирлау.

Административ процедураны башлау өчен әлеге Административ регламент таләпләренә кушымта итеп бирелә торган документлар пакеты белән үтенечнамәнең туры килүен билгеләү һәм әлеге Административ регламентның 2.8 бүлекчәсенең 2 пунктындагы 1-3 п.п. күрсәтелгән кире кагу өчен нигезләрнең булмавы нигез булып тора.

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы белгеч җирләрне яисә җир кишәрлекләрен мондый җирләр составында бер категориядән икенчесенә күчерү турында акт проектын әзерли.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе - шундый җирләрне бер категориядән икенчесенә күчерү турында акт кабул итү.

Гамәлләрне башкару срогы Бүлеккә үтенечнамә кергән көннән алып ике айдан артмаска тиеш.

3.5. Гариза бирүчегә документларны теркәгәндә һәм җибәргәндә (биргәндә) административ гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау.

Административ процедураны үтәү нәтиҗәсе булып гариза бирүчегә (гариза бирүче вәкиленә) түбәндәгеләрне җибәрү (бирү) була:

- җирләрне яисә җир кишәрлекләрен мондый җирләр составында бер категориядән икенчесенә күчерү турындагы акт;

- җирләрне бер категориядән икенчесенә күчерү турындагы үтенечнамәне яисә җир кишәрлекләрен бер категория җирләр составыннан икенчесенә күчерү турындагы үтенечнамәне караудан баш тарту;

- җирләрне яисә җир кишәрлекләрен мондый җирләр составында бер категориядән икенчесенә күчерүдән баш тарту.

Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен күчерү турындагы акт йә җирләрне яисә җир кишәрлекләрен күчерүдән баш тарту турындагы акт әлеге акт кабул ителгән көннән алып җиде көн эчендә кызыксынган затка җибәрелә.

3.6. Административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә, шул исәптән Бердәм портал яки  Региональ порталдан файдаланып гамәлгә ашыру тәртибе.

Муниципаль хезмәт турында мәгълүмат Бердәм порталда яисә Региональ порталда урнаштырыла.

Электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүгә гариза һәм аны бирү өчен кирәкле документларны кабул итү турында хәбәрнамә, муниципаль хезмәт күрсәтү турында соратуны үтәү барышы турында мәгълүмат, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталның яки Региональ порталның "Кулланучының шәхси кабинетына" җибәрелә.

3.6.1. Гаризаны һәм тапшырылган документларны кабул иткәндә һәм теркәгәндә гамәлләр эзлеклелеге тасвирламасы.

Электрон рәвештә муниципаль хезмәт күрсәтүне башлау өчен Бердәм порталдан яисә Региональ порталдан муниципаль хезмәт күрсәтүгә сорату Башкарма комитетының эчке электрон документ әйләнеше системасына керү нигез булып тора.

3.6.2. Үтенечнамәне караганда һәм муниципаль хезмәт күрсәтү турында яисә күрсәтелүдән баш тарту турында карар кабул иткәндә гамәлләрнең эзлеклелеге әлеге Административ регламентның 3 бүлегенең 3.3 һәм 3.4 бүлекчәләрендә күрсәтелгән эзлеклелеккә туры килә.

3.6.3. Гариза бирүчегә документларны теркәгәндә һәм тапшырганда гамәлләрнең эзлеклелеге тасвирламасы.

Җирләрне яисә җир кишәрлекләрен күчерү турындагы акт йә җирләрне яисә җир кишәрлекләрен күчерүдән баш тарту турындагы акт вәкаләтле вазыйфаи зат имзасыннан соң теркәүгә билгеләнгән тәртиптә җибәрелә һәм мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә).

Бердәм портал яки Региональ портал аша документлар тапшырылган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә Бердәм порталның яки Региональ порталның "Кулланучының шәхси кабинетына" җибәрелә.

Административ процедураны үтәү срогы 2 көннән арта алмый.

Әлеге Административ регламентта каралган административ процедураларны үтәү сроклары шул исәптән муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү срокларына да кагыла.

3.7. Күпфункцияле үзәкләр башкара торган административ процедуралар (гамәлләр) тасвирламасы.

